Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

«Янгын куркынычсызлыгы турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2005 елның 26 гыйнварында
кабул ителде

1 статья. «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, №11-12; 1994, №1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, №2, №11; 1999, №3; 2001, №3; 2002, №12 (II өлеш), яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Янгын куркынычсызлыгы турында»
Татарстан Республикасы Законы

Әлеге Закон Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

I бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу

Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу федераль законнар, әлеге Закон һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

2 статья. Татарстан Республикасы янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасы

1. Татарстан Республикасы янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасы – янгыннарга каршы көрәшкә юнәлдерелгән көчләр һәм чаралар, шулай ук хокукый, оештыру, икътисадый, социаль һәм фәнни-техник характердагы гамәлләр җыелмасы.

Татарстан Республикасы янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасының төп элементларын янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә законнар нигезендә катнашучы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар тәшкил итә.

Татарстан Республикасы янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасының төп функцияләре:

1) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә норматив хокукый җайга салу һәм дәүләт чараларын гамәлгә ашыру;

2) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә хокукларны, бурычларны һәм җаваплылыкны гамәлгә ашыру;

3) янгыннан саклауны булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру;

4) янгынга каршы пропаганда алып бару һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү;

5) янгыннан ихтыярый саклаучылар эшчәнлегенә ярдәм итү, халыкны янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә җәлеп итү;

6) янгын куркынычсызлыгын фәнни-техник тәэмин итү;

7) янгын куркынычсызлыгы өлкәсен мәгълүмати тәэмин итү;

8) янгын-техник продукциясе җитештерү;

9) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр;

10) янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару;

11) янгыннарны һәм алардан килгән зыяннарны исәпкә алу;

12) янгынга каршы махсус режим билгеләү.

II бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫНЫҢ ҺӘМ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ЯНГЫН КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

3 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге вәкаләтләре

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә законнар белән җайга салу;

республиканың янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мөһим программаларын раслау;

янгын куркынычсызлыгына, шул исәптән янгыннан саклануны тотуга чыгымнар өлешендә тиешле бюджетларны раслау;

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге законнарның үтәлешен контрольдә тоту.

4 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге вәкаләтләре

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итү;

янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

янгын куркынычсызлыгына, шул исәптән янгыннан саклануны тотуга чыгымнар өлешендә тиешле бюджетларны эшләү һәм үтәү;

халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру;

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә максатчан программалар эшләү, аларны башкаруны оештыру һәм финанслау;

үз компетенциясе чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүне, шул исәптән янгын-техник продукциясе җитештерүне һәм сатып алуны гамәлгә ашыру, шулай ук халыкның янгынга каршы көрәштә катнашуын социаль һәм икътисадый кызыксындыруны гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы янгыннан саклану шәхси составын һәм аларның гаилә әгъзаларын хокукый һәм социаль яклау чараларын күрү;

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтендә кимендә 25 ел эш стажы булганда, 50 яше тулгач, хезмәткәрләрнең картлык буенча пенсия хокукы бирә торган Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең оператив вазыйфалар исемлеген раслау;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тотыла торган янгыннан саклану идарәсе органнарын һәм бүлекчәләрен төзү, үзгәртеп кору һәм ликвидацияләү;

янгыннарны сүндерүне оештыру (илнең милли иминлеге өчен аеруча әһәмиятле объектлардагы янгыннардан, башка аеруча янгын чыгу куркынычы булган мөһим объектлардан, Россия мәдәни мирасының аеруча мөһим объектларыннан тыш, шулай ук исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган, халык күпләп тупланган федераль дәрәҗәдәге чаралар үткәргәндә;

Татарстан Республикасы акчалары исәбеннән финанслана торган янгыннан саклану хезмәтенең мәҗбүри рәвештә төзелә торган оешмалар исемлеген раслау;

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

5 статья. Җирле үзидарә органнарының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге вәкаләтләре

Җирлекләрнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү җирле үзидарә органнарының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге компетенциясенә керә.

Җирлекләрнең торак пунктлары, шәһәр округлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итүнең оештыру-хокукый, финанс, матди-техник мәсьәләләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

III бүлек. ЯНГЫННАН САКЛАНУ

6 статья. Татарстан Республикасы янгыннан саклануының төрләре һәм төп бурычлары

Татарстан Республикасы янгыннан саклануы түбәндәге төрләргә бүленә:
Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте;
муниципаль янгыннан саклану;
ведомство янгыннан саклану;
хосусый янгыннан саклану;
ирекле янгыннан саклану.
Янгыннан саклануның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:
янгыннарны кисәтүне оештыру һәм гамәлгә ашыру;
янгыннар вакытында кешеләрне һәм мөлкәтне коткару;
янгыннарны сүндерүне оештыру һәм гамәлгә ашыру, һәлакәттән коткару эшләрен уздыру.

Татарстан Республикасы янгыннан саклануы социаль-сәяси, милләтара конфликтларны һәм җәмәгать тәртибен масса төсендә бозуларны кисәтү, ликвидацияләү гамәлләренә җәлеп ителми.

7 статья. Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте Дәүләт янгынга каршы хезмәте составына керә һәм шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итү көчләренең состав өлеше булып тора.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелә.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте турында, аның структурасы һәм шәхси составының саны турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы янгыннарны сүндерү өлкәсендәге үз вәкаләтләренең бер өлешен башкаруны законнарда билгеләнгән тәртиптә янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә бурычларны хәл итүгә вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль хакимият органына тапшырырга хокуклы.

8 статья. Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең шәхси составы

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте шәхси составына махсус яисә хәрби дәрәҗәләре булмаган тиешле штат вазыйфаларындагы затларны (алга таба – хезмәткәрләрне) үз эченә ала.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенә яше 17дән ким булмаган, үзләренең шәхси һәм эшлекле сыйфатлары, белеме һәм сәламәтлеге торышы буенча Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең шәхси составына йөкләнгән вазыйфаларны үтәргә сәләтле гражданнар алына.

Хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән хокуклар, бурычлар һәм өстенлекле ташламалар Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләренә дә кагыла.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләре үзләренең профессиональ, социаль һәм башка хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында ихтыярый нигездә берләшергә яисә чыгыш ясарга һәм гамәлдәге законнар нигезендә янгыннан саклану һөнәр берлекләренә, ассоциацияләренә, берләшмәләренә керергә мөмкин.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең шәхси составы үз эшчәнлегендә сәяси максатларны күздә тотучы сәяси партияләр, массакүләм иҗтимагый хәрәкәтләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр карарлары белән чикләнә алмый.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең шәхси составына үз вәкаләтләрен раслау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә билгеләнгән үрнәктәге хезмәт таныклыклары бирелә.

9 статья. Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең шәхси составын хокукый һәм социаль яклау гарантияләре

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләре һәм аларның гаилә әгъзалары дәүләт яклавында була.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәре хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә һәлак булган очракта, аның гаиләсенең торак шартларын яхшыртуга, шул исәптән, аның һәлак булуы көненнән алты айдан да соңга калмыйча, аның һәлак булуы мизгеленә булган нигезләрдә аерым квартира алу хокукы сакланып кала.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең хезмәткәрләрен хокукый һәм социаль яклауның башка гарантияләре гамәлдәге законнар

нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм алар янгынга каршы федераль хезмәт хезмәткәрләрен хокукый һәм социаль яклауның гамәлләре гарантияләреннән ким булмаска тиеш.

10 статья. Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләренә иминләштерү гарантияләре

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте хезмәткәрләре законнар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән мәҗбүри рәвештә дәүләт тарафыннан шәхси иминләштерелергә тиеш.

11 статья. Татарстан Республикасы янгыннан саклануын финанслау һәм матди-техник тәэмин итү

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте бүлекчәләре эшчәнлеген, аның шәхси составына социаль гарантияләрне һәм компенсацияләрне Татарстан Республикасы законнары нигезендә финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсе булып тора.

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтен матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм нормалар буенча гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы тарафыннан законнар нигезендә янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына янгыннарны сүндерү өлкәсендә тапшырылган вазыйфаларның бер өлешен финанслау һәм матди-техник тәэмин итү әлеге федераль башкарма хакимият органы белән төзелгән килешү нигезендә билгеләнә.

Муниципаль берәмлек чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын, шул исәптән янгыннан ирекле саклануны финанс ягыннан тәэмин итү федераль законнар нигезендә муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәсе булып тора.

Янгыннан ведомство, хосусый һәм ирекле саклану эшчәнлеген финанс ягыннан һәм матди-техник тәэмин итү, шулай ук аларның шәхси составының социаль гарантияләрен һәм компенсацияләрен финанс ягыннан тәэмин итү федераль законнар нигезендә аларның гамәлгә куючылары тарафыннан үз акчалары исәбеннән башкарыла.

12 статья. Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең мөлкәте

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең мөлкәте хосусыйлаштырылмый.

13 статья. Муниципаль янгыннан саклану

Муниципаль янгыннан саклану муниципаль берәмлекләр территориясендә җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелә.

Муниципаль янгыннан саклану эшчәнлегенең максаты, бурычлары, аны төзү һәм оештыру тәртибе, янгыннан сакланунның башка хезмәтләре белән үзара мөнәсәбәтләре тәртибе җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

14 статья. Ведомство янгыннан саклану

Ведомство янгыннан саклану законнар нигезендә төзелә.

Ведомство янгыннан саклану идарә органнарын һәм бүлекчәләрен оештыру, үзгәртеп кору, ликвидацияләү тәртибе, аларның эшчәнлеген тормышка ашыру шартлары, шәхси составының хезмәт итүе федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә килешенгән тиешле нигезләмәләр белән урнаштырыла.

Ведомство буйсынуындагы оешмаларда янгын чыгу куркынычы һәм кешеләрнең иминлегенә зыян китерү куркынычы тудыра торган янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу ачыкланганда, ведомство янгыннан саклану оешманың (аерым производствоның), производство участогының, агрегатның эшен һәм бинадан, корылмадан, бүлмәдән файдалануны, кайбер эш төрләрен башкаруны тулысынча яисә өлешчә туктатып торырга хокуклы.

15 статья. Хосусый янгыннан саклану

Хосусый янгыннан саклану торак пунктларда һәм оешмаларда төзелә.

Хосусый янгыннан саклану бүлекчәләрен төзү, үзгәртеп кору, ликвидацияләү Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Хосусый янгыннан сакланунның саны һәм техник тәэмин ителеше нормативлары аның милекчесе тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

Хосусый янгыннан саклануы бүлекчәләре янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә төзелгән шартнамәләр нигезендә хезмәт күрсәтә.

16 статья. Ирекле янгыннан саклану

Ирекле янгыннан саклану — янгыннарны булдырмау, кешеләрне һәм мөлкәтне янгыннардан коткару буенча билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән нормаларны һәм кагыйдәләрне гамәлгә ашыруда гражданнарның катнашу рәвеше, ул янгын сүндерүне оештыру буенча чаралар комплексының бер өлеше булып тора.

Ирекле янгынчы - ирекле нигездә (хезмәт шартнамәсе төземичә) янгыннарны кисәтү һәм (яисә) сүндерү буенча янгыннан саклану бүлекчәләре эшчәнлегендә турыдан-туры катнашучы граждан.

Ирекле янгыннан саклануда катнашу җирлекләрнең һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә торган социаль әһәмиятле эшләр рәвеше булып тора.

IV бүлек. ЯНГЫН КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫН ТӘЭМИН ИТҮ

17 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу

Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу дәүләт хакимияте органнарының янгын куркынычсызлыгы буенча норматив хокукый актлар кабул итүеннән гыйбарәт.

Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә норматив җайга салу – вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан норматив документларда үтәү өчен мәҗбүри булган янгын куркынычсызлыгы таләпләрен билгеләү.

Янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларга янгын куркынычсызлыгы стандартлары, нормалары һәм кагыйдәләре, инструкцияләре һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләре булган башка документлар керә.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары үз компетенцияләре чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча федераль норматив документларда билгеләнгән янгын куркынычсызлыгы таләпләрен киметми торган норматив документлар әзерләргә һәм расларга хокуклы.

Янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар билгеләнгән тәртиптә теркәлергә һәм рәсми бастырылып чыгарылырга тиеш.

18 статья. Янгын куркынычсызлыгы чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру

Янгын куркынычсызлыгы чаралары Россия Федерациясе законнары нигезендә, янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларга таянып, шулай ук янгынга каршы көрәшү тәҗрибәсе, матдәләрнең, материалларның, технологик процессларның, әйберләрнең, конструкцияләрнең, биналарның һәм корылмаларның янгын куркынычлылыгын бәяләү нигезендә әзерләнә.

Матдәләр, материаллар, әйберләр һәм җайланмалар эшләүчеләр (кайтаручылар) тиешле техник документациядә әлеге матдәләрнең, материалларның, әйберләрнең һәм җайланмаларның янгын куркынычлылыгы күрсәткечләрен, шулай ук алар белән эш иткәндә янгын куркынычсызлыгы чараларын мәҗбүри күрсәтәләр.

Оешмалар, биналар, корылмалар һәм башка объектлар өчен янгын куркынычсызлыгы чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру, шул исәптән аларны проектлаганда да, янгыннар вакытында кешеләрне эвакуацияләүне тәэмин итүче карарларны мәҗбүри рәвештә күздә тотарга тиеш.

Производстволар өчен янгыннарны сүндерү буенча мәҗбүри рәвештә кешеләрнең иминлеген тәэмин итү карарларын күздә тотучы планнар әзерләнә.

Татарстан Республикасы торак пунктлары һәм административ берәмлекләр территорияләре өчен янгын куркынычсызлыгы чаралары Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан әзерләнә һәм гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары карары буенча әзерләнә торган инвестиция проектлары янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлешендә федераль законнарга туры китерелергә тиеш.

19 статья. Янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару

Янгыннарны сүндерү кешеләрне, мөлкәтне коткаруга һәм янгыннарны ликвидацияләүгә юнәлдерелгән гамәлләрдән гыйбарәт.

Янгыннан саклану хезмәте тарафыннан башкарыла торган һәлакәттән коткару эшләре кешеләрне, мөлкәтне коткару һәм (яисә) һәлакәтләр, бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр өчен характерлы куркыныч факторлар йогынтысын минималь ихтимал дәрәҗәгә кадәр киметү гамәлләреннән гыйбарәт.

Республика дәрәҗәсендә янгыннарны сүндерү өчен янгыннан саклану бүлекчәләре көчләрен һәм чараларын җәлеп итү тәртибе — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, җирле дәрәҗәдә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.

Торак пунктларга һәм оешмаларга янгыннарны сүндерү өчен янгыннан саклану бүлекчәләренең керүе һәм һәлакәттән коткару эшләрен алып бару мәҗбүри тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкачасы билгеләнмәсә, түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла.

Янгыннар һәм гадәттән тыш хәлләр турында торак пунктларның телефон челтәрләрендә хәбәрләр кабул итү өчен бердәм номер – 01 билгеләнә.

Янгыннарны сүндергәндә һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкарганда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, мөлкәтне коткару буенча, шул исәптән түбәндәге кирәкле гамәлләр башкарыла:

янгыннарның куркыныч факторларының, шулай ук һәлакәтләрнең, бәла-казаларның һәм башка гадәттән тыш хәлләрнең таралу (таралу мөмкинлеге) булган урыннарга үтеп керүе;

янгыннар, шулай ук һәлакәтләр, бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр булдыруга каршы килә торган һәм аларны бетерүне тәэмин итә торган шартлар тудыру;

кирәк очракта өстәмә рәвештә милекчедә булган элемтә, транспорт чараларыннан, җиһазлардан, янгын сүндерү чараларыннан һәм ут сүндерү матдәләреннән файдалану, алардан файдалануга бәйле мәсьәләләрне билгеләнгән тәртиптә алга таба хәл итү;

янгын сүндерү урыннарына, шулай ук һәлакәтләр, бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр зоналарына керүне чикләү яисә тыю, аларга карый торган территорияләрдә транспорт хәрәкәтен һәм җәяүлеләрнең йөрүен чикләү яисә тыю;

янгын сүндерү урыннарын, шулай ук һәлакәтләр, бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр зоналарын саклау (шул исәптән аларның килеп чыгу хәлләрен һәм сәбәпләрен тикшерү вакытында да);

янгыннар, һәлакәтләр, бәла-казалар, башка гадәттән тыш хәлләр урыннарыннан кешеләрне һәм мөлкәтләрне эвакуацияләү.

Янгын сүндерү белән турыдан-туры җитәкчелекне янгыннан саклану хезмәтенең янгын сүндерүгә килгән (әгәр башкасы билгеләнмәсә) шәхси составы, янгын сүндерүгә җәлеп ителгән көчләр белән бердәм башлангыч принципларында идарә итүче, янгын сүндерүдә катнашучы урындагы өлкән оператив заты гамәлгә ашыра.

Янгын сүндерү җитәкчесе куелган бурычлар өчен, янгыннан саклану хезмәтенең янгын сүндерүдә катнаша торган шәхси составының һәм янгын сүндерүгә җәлеп ителгән көчләрнең иминлеге өчен җавап бирә.

Янгын сүндерү җитәкчесе янгын сүндерү буенча гамәлләрне, күрсәтелгән гамәлләрнең тәртибен һәм үзенчәлекләрен гамәлгә ашыра торган территория чикләрен билгели, шулай ук кешеләрне, мөлкәтне янгыннан коткару турында карарлар кабул итә. Кирәк очракта янгын сүндерү җитәкчесе башка карарлар да, шул исәптән күрсәтелгән территориядә урындагы затларның һәм гражданнарның хокукларын чикли торган карарлар да кабул итә.

Янгын сүндерү җитәкчесенең күрсәтмәләре янгын сүндерү территориясендәге барлык урындагы затлар һәм гражданнар тарафыннан үтәлү өчен мәҗбүри булып тора.

Янгын сүндерү җитәкчесе гамәлләренә катнашырга яисә янгын сүндергәндә аның күрсәтмәләрен юкка чыгарырга беркемнең дә хокукы юк.

Янгыннан саклану хезмәтенең шәхси составы, янгын сүндерүдә, һәлакәтләр һәм бәла-казаларны бетерүдә катнашкан һәм аеруча кирәкле һәм (яисә) тәвәккәлек таләп ителүче шартларда эш иткән башка затлар килгән зыянны түләүдән азат ителәләр.

Янгын сүндергәндә янгыннан сакланунуң шәхси составы әйберләр рәвешендәге дәлилләрне һәм мөлкәтне саклау чараларын күрергә тиеш.

20 статья. Янгын-техник продукциясе җитештерү

Янгын-техник продукциясе дәүләт заказы һәм дәүләт оборона заказы нигезендә, шулай ук эшкуарлык эшчәнлеге тәртибендә башкарыла.

Дәүләт заказын һәм дәүләт оборона заказын башкару эшләрен оештыру гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

21 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр

Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр янгын куркынычсызлыгы таләпләрен гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук янгыннарны кисәтү һәм сүндерүне тәэмин итү максатларында башкарыла. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр исемлеге федераль законнар белән билгеләнә.

22 статья. Янгынга каршы пропаганда һәм янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү

Янгынга каршы пропаганда – массакүләм мәгълүмат чаралары аша, махсус әдәбият һәм регламент продукциясе тарату һәм бастыру, тематик күргәзмәләр, смотрлар, конференцияләр ярдәмендә һәм халыкка мәгълүмат бирү рәвешләренең Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чараларыннан файдаланып, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары хакында җәмгыятькә билгеле бер максатка юнәлдерелгән мәгълүмат бирү. Янгынга каршы пропаганданы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, янгыннан саклану хезмәте һәм оешмалары үткәрә.

Оешма хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү законнар нигезендә расланган махсус программалар буенча янгын куркынычсызлыгы турындагы норматив документлар нигезендә әлеге оешмаларның администрациясе (милекчеләре) тарафыннан башкарыла.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендәге балаларны һәм белем бирү учреждениеләрендә укучы затларны янгын куркынычсызлыгы чараларына мәҗбүри өйрәтү федераль законнар нигезендә килештерелгән махсус программалар буенча тиешле учреждениеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла. Мәгариф идарәсе һәм янгыннан саклану хезмәте органнары тарафыннан яшь янгынчыларның ирекле дружиналары төзелергә мөмкин. Күрсәтелгән затларны өйрәтү программалары эчтәлегенә таләпләр һәм аны оештыру тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.

23 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсен мәгълүмати тәэмин итү

Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасында куелган бурычларны үтәү өчен кирәкле махсус мәгълүмат системалары һәм белешмәләр банкы (алга таба – мәгълүмат системалары) төзү һәм алардан файдалану юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат системаларына янгын куркынычсызлыгы турындагы белешмәләрне керту нигезләре һәм тәртибе, шулай ук алар белән урындагы

затларны һәм гражданнарны таныштыру тәртибе янгын куркынычсызлыгы буенча федераль законнар һәм норматив документлар белән билгеләнә.

Татарстан Республикасының метеорология хезмәте һәм башка вәкаләтле дәүләт органнары янгын куркынычсызлыгы өчен уңайсыз вакыйгалар һәм фаразлар турында Татарстан Республикасы янгыннан саклануына кичектергесез рәвештә һәм түләүсез нигездә хәбәр итәргә тиеш.

Массакүләм мәгълүмат чаралары халыкның иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән ашыгыч мәгълүматны Татарстан Республикасы янгыннан саклануы таләбе буенча түләүсез нигездә һәм кичектергесез рәвештә бастырып чыгарырга тиеш.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары халыкка янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча кабул ителгән карарлар турында мәгълүмат бирергә һәм янгын-техник белемнәр таратуга ярдәм итәргә тиеш.

24 статья. Янгыннарны һәм аларның нәтиҗәләрен исәпкә алу

Татарстан Республикасында янгыннар һәм аларның нәтиҗәләре буенча рәсми статистик исәп һәм дәүләт статистика хисаплылыгы Россия Федерациясенең янгыннарны һәм аларның нәтиҗәләрен исәпкә алу буенча бердәм дәүләт статистика исәбе системасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

25 статья. Янгынга каршы махсус режим

Янгын куркынычы арткан очракта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары яисә тиешле территорияләрдә җирле үзидарә органнары карары белән махсус режим урнаштырылырга мөмкин.

Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорга тиешле территорияләрдә янгын куркынычсызлыгы буенча норматив хокукый документларда каралган өстәмә таләпләр билгеләнә.

26 статья. Янгын куркынычсызлыгын фәнни-техник яктан тәэмин итү

Янгын куркынычсызлыгын фәнни-техник яктан тәэмин итүне фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык, проект һәм башка фәнни-техник учреждениеләр һәм оешмалар, шулай ук тиешле уку йортлары гамәлгә ашыра.

Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә фәнни-техник эшләнмәләрне финанслау тиешле бюджет акчалары исәбеннән, шулай ук башка финанслау чыганаклары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

V бүлек. ЯНГЫН КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ХОКУКЛАР, БУРЫЧЛАР ҺӘМ ҖАВАПЛЫЛЫК

27 статья. Гражданнарның янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге хокуклары һәм бурычлары

Гражданнарның янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге хокуклары һәм бурычлары федераль законнар белән билгеләнә.

28 статья. Оешмаларның янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге хокуклары һәм бурычлары

Оешмаларның янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге хокуклары һәм бурычлары федераль законнар белән билгеләнә.

29 статья. Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган өчен җаваплылык

Гамәлдәге законнар нигезендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган өчен түбәндәгеләр җаваплы була:

мөлкәт милекчеләре;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре;

җирле үзидарә органнары җитәкчеләре;

мөлкәтне биләү, аннан файдалану яисә аның белән эш итүгә вәкаләтле затлар, шул исәптән оешмалар җитәкчеләре;

билгеләнгән тәртиптә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә җаваплы итеп билгеләнгән затлар;

үз компетенцияләре чикләрендә урындагы затлар.

Дәүләт, муниципаль һәм ведомство торак фонды йортларындагы квартирлар (бүлмәләр) өчен янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган өчен җаваплылык, тиешле шартнамә белән башкасы каралмаса, квартир хуҗасына яисә арендачыга йөкләнә.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән затлар, башка гражданнар янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган өчен, шулай ук янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә башка хокук бозулар өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылыкка тартылырга мөмкин.».

2 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыкканнан соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан,Кремль
2005 елның 26 феврале
№ 54-ЗРТ